**Карар**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге советы утырышы**

2019 елның 30 нчы декабре № 116

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 20 апрелендәге 22 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 22 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, һәм 15 статьяның 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, теркәлүне раслый торган документ;".

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Балтач авылы, Мәктәп ур., 1;
- ТР, Кама Тамагы районы, Балчыклы авылы, Мәктәп урамы, 2,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге башлыгы**
**Д.И.Мөхәммәдуллин**